**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ**

| **«КАРАЛДЫ»** | **«КИЛЕШЕНДЕ»** | **«РАСЛАНДЫ»** |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>__________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>__________Л.Р.Ягудина<br><br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>__________Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>**233** нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Хәбибрахманова Халисә Харис кызы
2 «Б» сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби укудан
эш программасы

Педагогик киңәшм
Утырышында каралд
Беркетмә №
31 август 2016 е

**2016 - 2017**

## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

Сыйныф: 2 “Б”
Укытучы: Хабибрахманова Х.Х.
Уку планы буенча
Татар теле һәм әдәби укудан: 136 сәг.
Атнага: 4 сәг.
Сүзлек диктанты: 2
Күчереп язу: 2
Тест: 5
Контроль эш: 4

Дәреслек: Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева, Г.М.Әхмәтҗанова ”Күңелле татар теле” Казан “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 ел.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

**Татар теленә өйрәтүнең предмет нәтиҗәләре.**

**Сөйләшу**

Диалогик сөйләм. 2 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага,раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

Монологик сөйләм. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**<u>Уку</u>**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

**<u>Язу</u>**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

- **Тыңлап аңлау**

-Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;

-тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

-сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.

-сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

-ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

- Диалогик сөйләм:

-Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага,раслый белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына жавап бирү һәм сораулар куя белү;

-дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

- **Монологик сөйләм**

-Җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

-тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

-укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;

-үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

- **Уку**

-Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;

-хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;

-дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;

-тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү,өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;

-укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
-кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
-укыганда сүзлекләр 4улана белү.

- **Язу**

-Татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
-дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
-бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;
-конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;
-программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

**Уку елы ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру. УУГ.**

**Шәхси нәтиҗәләр.**

**Шәхси универсаль уку гамәлләре:**

- “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;Предметара нәтиҗәләр.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү.( линейка, бетергеч, карандаш, )

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү

Планлаштырылган нәтиҗәләр

“Татар теле һәм әдәби уку” предметы буенча 2 нче сыйныф программасын үзләштерүнең шәхси нәтиҗәләре:

– татар теленең дәүләт теле буларак ролен аңлау;
– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;
– татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.
--Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

**Татар теленә өйрәтүнең метапредмет (регулятив, коммуникатив, танып-белү) нәтиҗәләре:**

–укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
–эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
–дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
–дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
–әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
–парларда һәм күмәк эшли белү;
–әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;
–үрнәк буенча эшли белү;
–аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
–рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
–аңлап укый белү;

укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирү - чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру

## II. Укыту предметының эчтәлеге

**Грамматик минимум**

1. Исемнең төшем килеше белән таныштыру.
2. Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрен сөйләмдә куллануны камилләштерү.
3. Исемнәрнең берлек санда 1,2 затта тартым белән төрләнешен сөйләмдә кулллануны камилләштерү.
4. Исемнәрнең берлек санда 3 затта тартым белән төрләнеше белән таныштыру (*аның китабы, сумкасы*).
5. Сыйфатның гади дәрәҗәсен сөйләмдә куллану.
6. 11дән 20 кадәр саннарны сөйләмдә куллану.
7. Мин, син зат алмашлыкларын юнәлеш килешендә сөйләмдә куллану.
8. Зат алмашлыкларын күплектә сөйләмдә куллану.
9. Кайчан? сорау алмашлыгы белән таныштыру.
10. Кем? Нәрсә? кайда? кая? кайдан? нинди? ничек? ничә? ничәнче? сорауларына җавап бирә, аларны кулланып, сорау бирә белүне камилләштерү.
10. Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,2,3нче зат юклык формасы белән таныштыру.
11. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта берлек сан 1,2,3нче зат формасы белән таныштыру.
12. Боерык фигыльнең барлык һәм юклык формалары белән таныштыру.
13. Кирәк, кирәк түгел, ярый, ярамый хәбәрлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
14. Чөнки теркәгечен сөйләмдә куллану.

**Орфографик и орфоэпик минимум.**

1. Сузык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен камилләштерү. Сингармонизм законы. Татар теленең үзенчәлекле сузыклары һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышы. Сүзләрне транскрипция билгеләре белән яза белү.
2. Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау авазлар. Алар кергән сүзләрне дөрес әйтә һәм язу күнекмәләрен камилләштерү.
3. Татар алфавитын яттан белү.
4. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Укылган иҗекләр санын билгели белү.
5. Аралашу өчен бирелгән темаларга караган сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешү.
6. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.

## III.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру.

| № | Дәрес темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|

| Тема: Без мәктәпкә барабыз (38 сәг.) | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Әдәпле сүзләр. | Сәнгатьле итеп сөйләү, уку. | 1.09 |
| 2. | Яңа уку елы белән!<br>-мы/-ме сорау кисәкчәсе; | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 2.09 |
| 3. | Яңа уку елы белән!<br>-мы/-ме сорау кисәкчәсе; | Диалог төзү. | 5.09 |
| 4. | Татар теленең хәреф-аваз системасы | Грамматик биремнәр үтәү. | 6.09 |
| 5. | Транскрипция билгеләре. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 8.09 |
| 6. | Калын һәм нечкә сузыклар | Грамматик биремнәр үтәү. | 9.09 |
| 7. | Кереш контроль эш | Кереш контроль эш. | 12.09 |
| 8. | Хаталар өстендә эш.<br>"Беренче сентябрь" тексты. | Хаталар өстендә эш , гамматик биремнәр эшләү. | 13.09 |
| 9. | Саннар. 1-10га кадәр саннар. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 15.09 |
| 10. | Тәртип саны | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 16.09 |
| 11. | Исемнең күплек сан кушымчасы | Грамматик биремнәр эшләү. | 19.09 |
| 12. | Фигыльнең башлангыч формасы. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 20.09 |
| 13. | Фигыльнең башлангыч формасы. | Диалог төзү. | 22.09 |
| 14. | Фигыльнең башлангыч формасы. | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 23.09 |
| 15. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-санда төрләнеше | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 26.09 |
| 16. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-санда төрләнеше | Таблица белән эшләү. | 27.09 |
| 17. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-санда төрләнеше | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 29.09 |
| 18. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы | Грамматик күнегүләр эшләү. | 30.09 |
| 19. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 3.10 |
| 20. | Исемнең урын-вакыт килеше. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 4.10 |
| 21. | Исемнең урын-вакыт килеше. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 6.10 |
| 22. | Исемнең урын-вакыт килеше. | Грамматик биремнәр эшләү. | 7.10 |
| 23. | Исемнең юнәлеш килеше | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 10.10 |
| 24. | Исемнең юнәлеш килеше | Диалог төзү. | 11.10 |
| 25. | Исемнең юнәлеш килеше | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 13.10 |
| 26. | Исемнең юнәлеш килеше | Лексик берәмлекләрне | 14.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үзләштерү. | |
| 27. | Исемнең чыгыш килеше. | Таблица белән эшләү. | 17.10 |
| 28. | Исемнең чыгыш килеше. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 18.10 |
| 29. | Исемнең чыгыш килеше. | Грамматик күнегүләр эшләү. | 20.10 |
| 30. | **Тест№1 “Без мәктәпкә барабыз”** | Контроль дәрес | 21.10 |
| 31. | Хаталар өстендә эш.<br>Исемнең чыгыш килеше. | Хаталар өстендә эш эшләү.<br>Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 24.10 |
| 32. | Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 25.10 |
| 33. | Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Таблица белән эшләү. | 27.10 |
| 34. | Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. итү. | 28.10 |
| 35. | Рус халык әкияте “Күмәч” | Әкиятне уку, тәрҗемә | 7.11 |
| 36. | Рус халык әкияте “Күмәч”не сәхнәләштерү. | Әкиятне рольләргә бүлеп уку, сәхнәләштерү. | 8.11 |
| 37. | Без мәктәпкә барабыз”темасын гомумиләштереп кабатлау. | Грамматик күнегүләр эшләү. | 10.11 |
| **Тема: Базарда - 12 сәгать** | | | |
| 38. | Яшелчәләр. | Яңа сүзләр өйрәнү. | 11.11 |
| 39. | Яшелчәләр. | **Сүзлек диктанты язу.** | 14.11 |
| 40. | Җиләк- җимешләр | Тәрҗемә итү, диалог төзү. | 15.11 |
| 41. | Җиләк- җимешләр | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 17.11 |
| 42. | “Базарда”тексты | Диалог төзү. | 18.11 |
| 43. | “Базарда”тексты | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 21.11 |
| 44. | “Базарда”тексты | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 22.11 |
| 45. | Көз билгеләре.<br>“Алтын көз тексты”. | Текесты сәнгатле итеп, тәрҗемә белән уку. | 24.11 |
| 46. | Көз билгеләре.<br>“Алтын көз тексты” өстендә эш. | Текесты сәнгатле итеп, тәрҗемә белән уку. | 25.11 |
| 47. | Көз билгеләре.<br>“Алтын көз тексты”. Без уйнарга чыгабыз. | Текст буенча грамматик биремнәр үтәү. | 28.11 |
| 48. | **Тест №2 “Көзге уңыш”** | Тест биремнәрен үтәү | 29.11 |
| 49. | Хаталар өстендә эш. “Көзге уңыш” темасын гомумиләштереп кабатлау. | Хаталар өстендә эш эшләү, ситуатив уеннар уйнау | 1.12 |
| **Тема: Мин чисталык яратам-16 сәгать** | | | |
| 50. | Шәхси гигиена предметлары. | Яңа сүзләр өйрәнү. | 2.12 |
| 51. | Шәхси гигиена предметлары.<br>“Алсу пөхтә кыз тексты”. | Текстны уку, тәрҗемә итү. | 5.12 |
| 52. | Шәхси гигиена предметлары.<br>“Алсу пөхтә кыз тексты” өстендә эш | Тәрҗемә итү, текст буенча грамматик биремнәр үтәү. | 6.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 53. | Тән әгъзаларының, исемнәре. Исемнәрнең 1нче затта тартым белән төрләнүе | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 8.12 |
| 54. | Тән әгъзаларының, исемнәре. Исемнәрнең 1нче затта тартым белән төрләнүе | Диалог төзү. | 9.12 |
| 55. | **Сүзлек диктанты №1.** Мин чисталык яратам**.** Исемнәрнең 2нче затта тартым белән төрләнүе | Сүзлек диктанты язу. | 12.12 |
| 56. | Хаталар өстендә эш.Исемнәрнең 2нче затта тартым белән төрләнүе | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 13.12 |
| 57. | Исемнәрнең 1, 2,3нче затта тартым белән төрләнүе. | Таблица буенча эшләү. | 15.12 |
| 58. | **Тест №3 “Мин чисталык яратам”** | **Контроль эш башкару** | 16.12 |
| 59. | Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эшләү. | 19.12 |
| 60. | Исемнәрнең 1, 2,3нче затта тартым белән төрләнүе. | Диалог төзү | 20.12 |
| 61. | “Марат авырый”тексты. | Текстны тәрҗемә белән уку. | 22.12 |
| 62. | “Марат авырый”тексты өстендә эшне дәвам итү. | Грамматик күнегүләр эшләү. | 23.12 |
| 63. | 1-100гә кадәр саннар. Хәл сорау. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 9.01 |
| 64. | “Мин чисталык яратам”темасын кабатлау | Грамматик күнегүләр эшләү. | 10.01 |
| 65. | “Мин чисталык яратам”темасын гомумиләштереп кабатлау | Проект эше башкару | 12.01 |
| **Тема: Кыш җитә -13 сәгать** | | | |
| 66. | Кыш айлары, кыш билгеләре. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 13.01 |
| 67. | “Кыш килә ”тексты. | Текесты сәнгатьле итеп, тәрҗемә белән уку. | 16.01 |
| 68. | Яңа ел бәйрәме. | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 17.01 |
| 69. | Яңа ел бәйрәме белән котлау. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 19.01 |
| 70. | Кышкы уеннар. | Үрнәк буенча диалог төзү. | 20.01 |
| 71. | Кая? Кайда?Кайдан? сорулары. | Диалог төзү. | 23.01 |
| 72. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең берлек санда зат белән төрләнеше. | Текст буенча грамматик биремнәр үтәү. | 24.01 |
| 73. | “Тауда” хикәясе. | Хикәяне сәнгатьле итеп, тәрҗемә белән уку. | 26.01 |
| 74. | Мин җимлек ясадым төзелмәсе. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 27.01 |
| 75. | “Гали җимлек ясады” тексты | Текстны тәрҗемә белән уку. | 30.01 |
| 76. | “Гали җимлек ясады” тексты өстендә эшне дәвам итү. | Текесты сәнгатьле итеп, тәрҗемә белән уку.Грамматик биремнәр үтәү. | 31.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 77. | **Тест № 4“Кыш”** | Тест биремнәре үтәү. | 2.02 |
| 78. | Хаталар өстендә эш.“Кыш” темасын гомумиләштереп кабатлау. | Хаталар өстендә эшләү. | 3.02 |
| **Тема: Безнең гаилә-11 сәгать** | | | |
| 79. | “Безнең гаилә” | Яңа сүзләр өйрәнү. | 6.02 |
| 80. | “Безнең гаилә” хикәясен төзү. | Тема буенча телдән хикәя төзү. | 7.02 |
| 81. | Кемне? Нәрсәне? Сорулары. | Диалог төзү. | 9.02 |
| 82. | Ш. Маннурның “Яратам”шигыре | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 10.02 |
| 83. | Татар халык ашлары. | Лексик берәмлекләрне үз ләштерү. | 13.02 |
| 84. | ”Айдар бездә кунакта” хикәясе | Текстны уку, грамматик биремнәр эшләү. | 14.02 |
| 85. | Өй хезмәте. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 16.02 |
| 86. | “Безгә кунаклар килде” тексты. | Грамматик биремнәр эшләү | 17.02 |
| 87. | “Майны кем ашады?”тексты | Текстны уку, грамматик биремнәр эшләү. | 20.02 |
| 88. | **Тест №5 “Безнең гаилә”** | Тест биремнәрен үтәү. | 21.02 |
| 89. | Хаталар өстендә эш.“Безнең гаилә” темасын гомумиләштереп кабатлау | Хаталар өстендә эш эшләү. Проект эшен башкару. | 23.02 |
| **Тема: Яз килә -8 сәгать** | | | |
| 90. | Яз билгеләре. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 24.02 |
| 91. | “Яз җитә” шигыре. | Шигырьне уку, тәрҗемә итү. | 27.02 |
| 92. | Контроль күчереп язу | Контроль эш башкару. | 28.02 |
| 93. | Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эшләү, грамматик биремнәр үтәү. | 2.03 |
| 94. | “Яз җитә” шигырен ятлау. | Көйгә салып җырлау. | 3.03 |
| 95. | 8 нче Март – әниләр бәйрәме | Телдән открытка төзү. | 6.03 |
| 96. | **Тест №6 “Яз”** | Тест биремнәрен үтәү. | 7.03 |
| 97. | “Яз” темасын гомумиләштереп кабатлау | Проект эше башкару. | 9.03 |
| **Тема: Мин Татарстанда яшим-14 сәгать** | | | |
| 98. | Татарстан – минем туган ягым. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 10.03 |
| 99. | Татарстанның табигате | Сәнгатьле итеп уку, тәрҗемә итү. | 13.03 |
| 100. | Татарстанның табигате турында сөйләү. | Сорауларга җавап бирү. | 14.03 |
| 101. | Татарстан шәһәрләре. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 16.03 |
| 102. | Син кайда яшисең? | Үрнәк буенча диалог төзү. | 17.03 |
| 103. | “Минем туган ягым” хикәясен төзү. | Телдән текст төзү. | 30.03 |
| 104. | Без шәһәрдә яшибез. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 31.03 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 105. | Светафорның өч күзе. | Грамматик биремнәр эшләү. | 3.04 |
| 106. | “Юлда” тексты. | Текстны уку, грамматик биремнәр эшләү. | 4.04 |
| 107. | Юл аша чыгам, юл аша чыкмыйм төзелмәсе. | Ситуатив уен уйнау, лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 6.04 |
| 108. | Мин авылда яшим. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 7.04 |
| 109. | Муса Җәлилнең “Әтәч ”шигыре | Шигырьне уку, тәрҗемә итү. | 10.04 |
| 110. | **Тест№7 “Мин Татарстанда яшим”** | **Тест биремнәрен үтәү.** | 11.04 |
| 111. | Хаталар өстендә эш. “Мин Татарстанда яшим” темасын гомумиләштереп кабатлау” | Хаталар өстендә эшләү. | 13.04 |
| **Тема: Кибеттә- 11сәгать** | | | |
| 112. | Киемнәр кибетендә. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 14.04 |
| 113. | “Киемнәр кибетендә” диалогы төзү | Диалог төзү. | 17.04 |
| 114. | “Киемнәр кибетендә” темасын өйрәнүне дәвам итү. | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 18.04 |
| 115. | “Матур киемнәр”тексты. | Текстны уку, грамматик биремнәр эшләү. | 20.04 |
| 116. | Айгөл акыллы кыз. (Образны бәяләү). | Сораулар буенча образга бәя бирә белү. | 21.04 |
| 117. | Кибеттә сату – алу. | Ситуатив рольле уен уйнау. | 24.04 |
| 118. | Ашамлыклар кибетендә | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 25.04 |
| 119. | “Ашамлыклар кибетендә” диалог төзү. | Үрнәк буенча диалог төзү. | 27.04 |
| 120. | “Ашамлыклар кибетендә” темасын кабатлау | Грамматик биремнәр эшләү. | 28.04 |
| 121. | **Тест №8 “Кибеттә”** | **Тест биремнәрен үтәү.** | 1.05 |
| 122. | Хаталар өстендә эш.“Кибеттә” темасын гомумиләштереп кабатлау | Хаталар өстендә эш эшләү. | 2.05 |
| **Тема: Җәй-13 сәгать** | | | |
| 123. | Ямьле җәй җитте | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 4.05 |
| 124. | “Ямьле җәй җитте” тексты | Текстны тәрҗемә белән уку. | 5.05 |
| 125. | **Сүзлек диктанты “Җәй”** | Сүзлек диктанты язу. | 8.05 |
| 126. | Хаталар өстендә эш. | Хаталар өстендә эш, грамматик биремнәр башкару. | 9.05 |
| 127. | М. Газизовның “Балан” шигыре | Шигырьне уку, тәрҗемә итү. | 11.05 |
| 128. | М.Газизовның “Балан” шигыре өстендә эшне дәвам итү. | Шигырьне сәнгатьле итеп уку. | 12.05 |
| 129. | Без Сабантуйга барабыз. | | 15.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 130. | Сабантуйда кем нишли? | Рәсем буенча хикәя төзү. | 16.05 |
| 131. | Сабантуй- күңелле бәйрәм. | Үрнәк буенча хикәя төзү. | 18.05 |
| 132. | **Еллык контроль эш** | Контроль эшне башкару. | 19.05 |
| 133. | Хаталар өстендә эш | Хаталар өстендә эшләү | 22.05 |
| 134. | Үткәннәрне кабатлау | Диалог төзү. | 23.05 |
| 135. | Йомгаклау дәресе | Лексик берәмлекләрне үзләштерү. | 25.05 |
| 136. | Йомгаклау дәресе | Грамматик биремнәр эшләү. | 26.05 |

Пронумеровано прошнуровано
И скреплено печатью
10 /десять/ листов
Учитель татарского языка и
Литературы Хабибрахманова Х.Х.